# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле
органнары турында" Татарстан Республикасы
Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү
хакында

I. "Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. 4 статьяның 3 өлешендәге "бер үк вакытта дәүләт хакимиятенең җирле вәкиллекле органнарына сайлаулар билгеләгән килеш" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

2 статья. 13 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 4,5 өлешләрне өстәргә:

"Халык депутатларының берләштерелгән Советлары берләштерелүче Советларның территорияләрендә әлеге статьяның 2 өлешендә санап кителгән үзләренең барлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

Халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле хакимиятләр әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән тәртиптә берләштерелгән очракта, шәһәрләрдәге район хакимиятләреннән гайре, халык депутатларының берләштерелүче Советларының һәм җирле хакимиятләрнең вәкаләтләре алар берләшкән көннән туктатыла, ә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле хакимиятләр халык депутатларының берләштерелгән Советлары һәм берләштерелгән җирле хакимиятләре дигәнне аңлата".

3 статья. 15 статьяның 4 өлешенә түбәндәге сүзләрне өстәргә: ",ә берләштерелгән Советныкын, аның рәисен сайлаганчы, килешү буенча берләштерелгән Советларның рәисләреннән берәрсе...".

4 статья. 17 статьяга түбәндәге эчтәлектәге өлеш өстәргә: "Советларны әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән тәртиптә берләштергән очракта әлеге Советларның халык депутатлары берләштерелгән Совет төзелгән көннән халык депутатларының берләштерелгән Совет халык депутаты статусын алалар, аларның вәкаләтләре сайлану чоры буена саклана. Берләштерелгән Советларның халык депутатлары үзен сайлаган сайлаучылары алдында җаваплы була һәм хисап тота".

5 статья. 26 статьяга түбәндәге эчтәлектәге өлеш өстәргә: "Берләштерелгән җирле хакимиятләр берләштерелүче хакимиятләр территорияләрендә әлеге статьяның 1 өлешендә санап кителгән үзләр нең барлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар".

6 статья. 27 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 4 өлешне өстәргә:

"Халык депутатлары Советлары гомуми хакими үзәге булган административ-территория берәмлекләренә берләштерелгән очракта район һәм шәһәр хакимияте башлыгы, районнарга бүленгән шәһәр хакимияте башлыгы халык депутатларының берләштерелгән Советы ризалыгы белән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

Әлеге статьяның 4,5,6,7,8,9 өлешләрен 5,6,7,8,9,10 өлешләр дип санарга.

II. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 25 мае
N 87